

Үткән атнада Ләмберә районы Черемиш топ мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучыларынын муниципаль семинар-кинәшмәсе vтте.
Урнашылган традиция буенча, Ләмберә районы мәгариф бvлеге («ЦИМО МОУ» МКУ) методисты Линара Аллям кызы Муртазина житәкчелегендә, татар теле һәм татар әдәбияты укытучылары эш тәжрибәләре белән уртаклашалар, заман технологияләрен vзләштерәләр, аралашалар.       Шулай, vткән атнада да Черемиш мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучыларынын «Укучыларнын уку һәм дәрестән тыш эшчәнлегендә туган (татар) телен һәм татар әдәбиятын ойрәнvгә мотивацияне арттыру» дигән семинарда Ләмберәнен беренче урта мәктәбеннән Алмаз Кериш кызы Янгляева, Ләмберәнен икенче урта мәктәбеннән Галия Асият кызы Ахметова, Кривозерье урта мәктәбеннән Луиза Низаметдин кызы Смакаева, Аксён урта мәктәбеннән Альфия Шайхетдин кызы Абдюшева, Пензятка урта мәктәбеннән Равза Мукаддяс кызы Юмаева, Татар Тавла топ мәктәбеннән Альфия Фатих кызы Мортазина, Черемиш топ мәктәбе укытычысы Фазия Фәрит кызы Боярова катнаштылар.
Семинарнын практик олеше 9 нчы сыйныфта Нажар Нәжминен «Татар теле» шигырен ойрәнv темасына ачык татар әдәбияты дәресе белән башланды. Бирелгән ребусны чишеп, укучылар дәреснен темасын vзләре билгеләделәр. Аларга гомере буе тырышып ана телен укыткан укытучылары Фазия Фәрит кызы Боярова презентация ярдәмендә шагыйрьнен кыскача биографиясе белән таныштырды. Габдулла Тукайнын «Туган тел» шигырен яттан белгәнгә, бергәләп шагыйрь сvзләренә язылган «Туган тел» жырын рәхәтләнеп башкардылар. Нажар Нәжми шигырен ойрәнv 9 класс укучысы Азисова Әминәнен Нажар Нәжминен «Татар теле» шигырен сәнгатьле яттан укуы белән дәвам итте. Дәрестә текст белән эшләv этабы «Татар теле» шигыреннән юллар белән сорауларга жавап табудан гыйбарәт иде. Укучылар шигырьдән озекләрне сәнгатьле итеп укыдылар, яхшы белемнәрен һәм шигърият әсәрләрен анализлый белvләрен кvрсәттеләр. Аймранов Самир белән Петров Роман «Ярминкәгә» дигән сценка кvренешендә татар теле - ин матур тел һәм аны рус сvзләре белән чvпләмәскә кирәк дигән фикерне әйттеләр.



Семинарнын эше Татар Тавла топ мәктәбе укытучысы Альфия Фатих кызы Мортазинанын «Татар халкынын традицияләре һәм мәдәнияте» дигән мастер-классы белән дәвам итте. Мастер-класста катнашучылар оч кафеда булдылар: «Татар халкынын гореф-гадәтләре һәм йолалары», «Татар халык әкиятләре», «Татарларнын милли ашлары». Һәр кафеда катнашучылар vз проектлары очен бик кvп кызыклы әйберләр таптылар.
Пензятка урта мәктәбе укытучысы Рауза Мукаддяс кызы Юмаева мастер - классында укытучыларны да, тугызынчы сыйныф укучыларын да китап кыстыргычларын бизәv очен татар милли орнаментын кулланырга ойрәтте. Һәр катнашучы vзенен ин матур тамгасын

ясады.
Ләмберә районы мәгариф бvлеге методисты Линара Аллям кызы Мортазина укытучыларны педагогик хезмәткәрләр аттестациясе яна-лыклары белән таныштырды һәм семинарга нәтиҗә ясагач, эш тәҗрибәләре белән уртаклашкан Фазия Фәрит кызы Бояровага, Альфия Фатих кызы Мортазинага, Рауза Мукаддяс кызы Юмаевага Сертификатлар тапшырды.
Кунаклар оештыручыларга кызыклы һәм эчтәлекле чара vткәргәннәре очен рәхмәт белдерделәр, семинарга югары бәя бирделәр, анын нәтиҗәлелеген, актуальлеген һәм гамәли юнәлешлелеген билгеләп vттеләр. Семинарда катнашучыларнын барысы да яна белем һәм кvнекмәләр генә тvгел, ә алга таба эшләv очен «яна сулыш» алдылар.

*Наилэ НАСЫРОВА*